# БӨЕКБРИТАНИЯ ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫ ИР-АТЛАР АРАСЫНДА ИРЕКЛЕ СТИЛЬ БЕЛӘН 4Х200 ЭСТАФЕТАДА АЛТЫН МЕДАЛЬГӘ ЛАЕК БУЛДЫ

07.08.2015, 19:19

СПОРТ

**Бу минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында соңгы финал йөзеше тәмамланды. Ир-атлар арасында ирекле стиль белән 4х200 эстафетада планетаның иң яхшы 8 җыелма командасы ярышты.**

Британиялеләр иң җитезләр булып чыктылар, 7:04.33 секундлы нәтиҗә белән хаклы рәвештә алтын медальгә хуҗа булдылар. Алар артыннан финишка Америка командасы килеп җитте, алар күрсәткән нәтиҗә - 7:04.75. Призлы өчлекне Австралия җыелма командасы япты, аларның нәтиҗәсе - 7:05.34.

ДЧ-2015. Йөзү

Ир-атлар. Эстафета, ирекле стиль, 4х200 м.

1. Бөекбритания – 7:04.33

2. АКШ - 7:04.75

3. Австралия - 7:05.34

7 август. Казан. “Казан Арена”

Су спорт төрләре буенча 16 нчы дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА